**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12.02.2015 № 140

Татарстан Республикасы Нурлат районы буенча 2015 елга эпизоотиягә каршы чаралар планын раслау турында

"Татарстан Республикасында ветеринария эше турында" 13.07.1993 ел, № 1934-XII ТР Законын үтәү максатында, йогышлы һәм паразитар авырулар таралуны булдырмау, йогышлы булмаган авыруларны профилактикалау, шулай ук сәламәт һәм сыйфатлы терлекчелек продукциясе алу өчен

КАРАР БИРӘМ:

1. 2015 елга Татарстан Республикасының Нурлат районында эпизоотиягә каршы чараларны уздыру планын расларга.

2. Авыл хуҗалыгы производствосы җитәкчеләренә 2015 елга лейкозны тикшерү планын һәм 2015 елга эпизоотиягә каршы чаралар планын үтәүне, шулай ук кирәкле биопрепаратлар, медикаментлар, дезинфекцияләү чараларын сатып алуны тәэмин итәргә киңәш итәргә.

3. “Эпизоотиягә каршы чараларның үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районының "Нурлат район ветеринария берләшмәсе" ДБУ башлыгы В. А. Лысовка йөкләргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен Нурлат муниципаль районы һәм Нурлат шәһәре авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы И. С. Сафиуллинга йөкләргә.

Җитәкче А.К. Габдуллин